Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советының унөченче утырышы

Питрәч авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

27 май, 2022 ел № 44

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 01.04.2022 елның 90-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советында муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советында муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советының 2016 елның 20 апрелендәге 32 номерлы карары белән расланган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәнең 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 5 пунктта «ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре

тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокта» сүзләренә алмаштырырга;

- 8 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пай җирләре), хисап чорында цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча чыгымнары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса һәм әлеге алыш-бирешләрне башкару чыганаклары хакында.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы И.М. Кашапов